ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 26 от 28 марта 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 1 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль законның 31 статьясы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы №1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында" Татарстан Республикасы Президенты Указы, Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 1 февралендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 6 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Зиатдинов